Татарстан Республикасы Президенты Указы

**Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында**

Татарстан Республикасы алдында казанышлары булган Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыксыз затларны бүләкләү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзен гамәлгә куярга.

2. 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе тасвирламасын расларга.

3. Әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы бюджетының Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген тәэмин итүгә каралган акчалары исәбенә башкарырга.

4. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенә Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе бланкларын әзерләүне әлеге Указ белән расланган тасвирлама нигезендә тәэмин итәргә, шулай ук әлеге Указны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2011 ел, 27 декабрь
№ ПУ-873